СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**« 22 » май 2024 ел** **№ 284**

**Арча район Советының 2018 елның 13 октябендәге 199 номерлы карары белән расланган Арча муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (14.03.2019 N 230, 13.11.2019 N 286, 05.02.2020 N 302, 11.12.2020 N 33, 20.04.2021 N 54, 14.09.2021 N 80, 31.01.2023 N 187, 24.03.2023 N 198, 25.08.2023 N 227 үзгәрешләр белән)**

«Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында» Федераль законның 12 статьясына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 12 декабрендәге 594-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 79 статьясына һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 28_1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 23 мартындагы 54-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы федераль законнар, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 34.1 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2024 елның 29 апрелендәге 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, Арча район Советы карар бирде:

1. Арча район Советының 2018 елның 13 октябендәге 199 номерлы карары белән расланган Арча муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (14.03.2019 N230, 13.11.2019 N 286, 05.02.2020 N 302, 11.12.2020 N 33, 20.04.2021 N54, 14.09.2021 N80, 31.01.2023 N187, 24.03.2023 N198, 25.08.2023 N 227 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1) 9.1. пунктны түбәндәге эчтәлектәге 12 пунктча белән тулыландырырга:**

«12. «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 02.03.2007 ел, 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15_2 статьясында каралган анкетадагы мәгълүматларның (алга таба- анкетадагы белешмәләрнең) аңа билгеле булган үзгәрешләре турында яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) язма рәвештә хәбәр итәргә.»

**2)10.1 пунктның 8 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«8) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм (яки) аны үткән вакытта муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулаган чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәүне раслаучы ялган мәгълүматлар һәм (яки) ялган документлар тапшыру, яисә

муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулый торган чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәү турында документлар һәм (яки) мәгълүматлар тапшырмау;»;

3) **түбәндәге эчтәлектәге 19.2 пунктча белән тулыландырырга:**

«19.2. Анкетаны тапшыру, мәгълүматның үзгәрүе турында хәбәр итү, анкетада булган мәгълүматны кертү һәм мондый мәгълүматны тикшерү.

1. Муниципаль хезмәткә кергәндә граждан анкета тапшыра.

2. Муниципаль хезмәткәр яллаучы (эш бирүче) вәкиленә анкетада булган мәгълүматларның аңа билгеле булган үзгәрешләре турында язма рәвештә хәбәр итә.

3. Анкета формасы, шул исәптән анда кертелгән мәгълүматлар исемлеге, аларны актуальләштерү тәртибе һәм вакыты Россия Федерациясе Президенты тарафыннан билгеләнә.

4. Анкетада булган мәгълүматлар яллаучы (эш бирүче) вәкиле яки ул вәкаләт биргән зат карары буенча тикшерелергә мөмкин. Анкетада булган мәгълүматларны тикшерү муниципаль органның кадрлар хезмәте тарафыннан тиешле мәгълүматка ия булган иҗтимагый хакимият органнарына һәм оешмаларга язма рәвештә, шул исәптән дәүләт мәгълүмат системалары аша, запрослар җибәрү юлы белән башкарыла. Тиешле мәгълүматка ия булган җәмәгать хакимияте органнары һәм оешмалары соралган мәгълүматны әлеге соратуны алганнан соң бер айдан да соңга калмыйча бирергә тиеш.»;

**4) 14.3 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«2) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15_2 статьясында каралган анкета»;

**5) 14.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«14.4. Гражданның әлеге нигезләмәсе нигезендә муниципаль хезмәткә кергәндә бирелгән мәгълүматлары (анкетада булган мәгълүматлардан тыш) федераль законнар нигезендә тикшерелергә мөмкин.»;

**6) 27.11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«27.11. муниципаль хезмәткә кергәндә һәм аны үткән вакытта муниципаль хезмәткәрләргә граждан тарафыннан тапшырыла торган мәгълүматларны тикшерүне оештыру һәм үткәрү;»;

**7) түбәндәге эчтәлектәге 27.11.1 пунктча белән тулыландырырга:**

«27.11.1 дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматка билгеләнгән форманы кертүне рәс**миләштерү;»;**

**8) 28.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«28.7. «Максатчан уку турында килешү төзү конкурсында катнашу хокукына Россия Федерациясенең дәүләт телен белгән, тиешле дәрәҗәдәге һөнәри белем алучы һәм укуны тәмамлаганнан соң хезмәт мөнәсәбәтләре барлыкка килүгә китерә торган уку яки башка килешү буенча йөкләмәләре булмаган гражданнар ия. Әлеге конкурста катнашучы граждан муниципаль хезмәткә кергәндә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 33 пунктында каралган барлык срок дәвамында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль закон белән билгеләнгән таләпләргә туры килергә тиеш.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http:arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча район Советының законлылык, җәмәгать тәртибен саклау һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
Арча район Советы рәисе И.Г. Нуриев